ГЛАВА
САРСАК-ОМГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САРСАК-УМГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.10.2024 Сарсак-Умга авылы № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Сарсак-Умга авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Сарсак-Умга авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге башлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Сарсак-Умга авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Сарсак-Умга торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2024 елның 7 ноябрь көнне 14 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Сарсак-Умга авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Сарсак-Умга торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2024 елның 7 ноябрь көнне 15 сәгать 30 минутта билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә:

-1 этап: Сарсак-Умга авылы Ворошилов ур., Береговая ур., К. Маркс ур. 1 - 58 нче йортлар.

-2 этап: Сарсак-Умга авылы Ленин ур., Логовая ур., Красноармейская ур., Яшьләр ур., Киров мәйданы, К.Маркс ур. 59-76 нчы йортлар.

4. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы “Сарсак-Умга авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Сарсак-Умга торак пункты

территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар (80 яшькә җиткән), студентлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ирекле рәвештә киткәннәрдән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (аларның ата-аналарын, хатыннары, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итеп һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне үтәү буенча алынган мәсьәләләрне хәл итүгә юллап, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдереп, гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: 2025 елда үзара салым акчасын 700 сум күләмендә кертү һәм куллану белән килешәсезме?":

- электр челтәрләрен тышкы яктырту, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (электр товарларын сатып алу һәм лампаларны, фонарьларны алмаштыру һәм урамнарны яктырту чыгымнарын тоту буенча башка чыгымнар);

- Сарсак-Умга торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү,ремонтлау, карап тоту (Ленин урамындагы, Заречная урамындагы, Ворошилов урамындагы чокырларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу һәм салу һәм автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә (Сарсак-Умга торак пунктында сантехник һәм чыгым материаллары сатып алу, сүүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар );

- торак пункт территориясен төзекләндерү (үләнне чаптыру, авария хәлендәге һәм коры яшел үсентеләрне кисү, торак пункт урамнары юлларын кардан чистарту һәм территорияне төзекләндерү буенча башка чыгымнар)

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Сарсак-Умга авылы, Киров мәйданы, 15 нче йорт, авыл мәдәният йорты.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлегенең мәгълүмат стендында игълан итәргә, «Интерне» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль

районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Т.С. Николаева